Килешенде:
Муниципаль бюджет учреждениесе
“Мәгълүмати-методик үзәк” директоры
_________ Н. А. Нестерова

Раслыйм:
Муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “55 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе” директоры
_____________________ Ч.Г.Подъячева

Факил Сафин иҗатына багышланган
укытучыларның, китапханә хезмәткәрләренең һәм укучыларның
V төбәкара фәнни-гамәли конференциясе

# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## I. Гомуми мәгълүмат

1.1. Нигезләмә күренекле прозаик, шагыйрь, тәрҗемәче, әдәбият галиме, публицист, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Язучылар берлеге һәм Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Гаяз Исхакый, Александр Грибоедов, Габдулла Тукай исемендәге әдәби премияләр лауреаты күренекле әдип - Факил Сафин иҗади мирасын киңрәк өйрәнү һәм популярлаштыру максатын, бурычларын, тәрибен билгели.
Конференциянең үткәрү тәртибе, алымнары үзгәрергә мөмкин.
1.2. Конференция гомуми белем бирү оешмаларында туган (татар) тел һәм әдәбиятыннан башлангыч, төп һәм урта белем бирү программаларын гамәлгә куючы педагогларны берләштерә.

## II. Конференциянең максаты һәм бурычлары

2.1. Туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучыларын, китапханә хезмәткәрләрен һәм укучыларны фәнни-эзләнү эшләренә тарту.
2.2. Бурычлары:
- Факил Сафинның иҗади мирасын киңрәк өйрәнү һәм пропагандалау;
-укучыларда телебезгә, милли гореф-гадәтләребезгә, рухи байлыгыбызга мәхәббәт тәрбияләү;
-фәнни эзләнүдә иҗадилыкка омтылыш һәм кызыксыну тәрбияләү;
-татар халкының мәдәни-тарихи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту;
-сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру;
Укытучыларның алдынгы тәҗрибәсен барлау, эзләнү эшенә тартып, аларны фәнни эшләргә җәлеп итү.

## III. Конференцияне оештыручылар

3.1. Конференцияне оештыручылар:

-Яр Чаллы шәһәр Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;

-Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет учреждениесе “Мәгълүмати-методик үзәк”;

-Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “55 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”

## IV. Конференциядә катнашучылар

4.1. Конференциядә гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучылары, китапханә хезмәткәрләре, 5-11 нче сыйныф укучылары катнаша ала.

## V. Конференциянең эш юнәлешләре

5.1. Факил Сафин иҗатына багышланган укытучыларның, китапханә хезмәткәрләренең һәм укучыларның V төбәкара фәнни-гамәли конференциясе

1- Факил Сафин – күпкырлы талант иясе.

2 - Факил Сафин шигърияттә.

3 - Факил Сафин прозада.

4 - Факил Сафин әсәрләрен сәнгатьле сөйләү бәйгесе (авторның 1 әсәре алына).

<u>Укучылар өчен</u>: фәнни-гамәли эш, сәнгатьле сөйләү бәйгесе;

<u>Укытучылар, китапханә хезмәткәрләре өчен</u>: фәнни-гамәли эш.

## VI. Фәнни-гамәли конференция чыгышларына таләпләр

6.1. Фәнни-гамәли конференция чыгышлары түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

<u>1. Фәнни-гамәли эш белән катнашучылар өчен:</u>

-чыгыш ясаучының теманы ачып бирә алуы;

-аргументлаштырылган һәм иҗади фикерләү сәләтенә ия булу;

-грамоталы, әдәби телдә язылган булуы, мисал итеп китерелгән фактларның дөрес булуы шарт;

-хезмәтләрне күрсәтмә материаллар, презентация белән баету;

-куелган проблема буенча әдәбият, чыганакларны куллану, эшләрдә сылтамалар дөрес куелу.

<u>2. Факил Сафин әсәрләрен сәнгатьле сөйләү бәйгесендә катнашучылар өчен:</u>

- бирелгән темадан тайпылмау;

- сәнгатьлелек, тел-сөйләм төзеклеге һәм матурлыгы;
- әдәби әсәрнең эчтәлеген ача белү;
- башкаручының үз-үзен тота белүе.

6.2. Фәнни-гамәли хезмәтләр бары тик татар телендә генә кабул ителә.

6.3. Хезмәтнең язылу тәртибе.

Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифтTimes New Roman-14интервал 1,5, уңнан -1,5; сулдан-2,5; астан-2; өстән -1,5 ) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла һәм кире кайтарылмый.

Титул битенә белем бирү учреждениесенең тулы исеме, сыйныфы, тема, эшнең юнәлеше һәм җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

Республикакүләм башка конкурсларда катнашып призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.

Конференциядә чыгыш ясау вакыты 3-5 минут. Катнашучы шушы вакыт эчендә эчтәлекне ачып, төп фикерләрен күрсәтеп бирергә тиеш. Компьютер презентациясе хуплана.

Эшләр электрон вариантта кабул ителә.

## VII. Конференцияне үткәрү тәртибе

7.1.Оештыру комитеты конференциядә катнашу өчен гаризаларны сайлап алу хокукын үзендә калдыра.

7.2. Конференция Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “55 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”ндә үткәрелә.

7.3. Конференция 2026 нчы елның 6 нчы февралендә читтән торып яклау формасында (заочная форма) уздырыла. Катнашу өчен заявка, фәнни-гамәли эшләрне, сәнгатьле сөйләү бәйгесендә катнашучылар - видео ссылкасын 2026 нчы елның 30 нчы гыйнваренә кадәр ia.gulnur64@mail.ru электрон адресына җибәрергә.

Элемтәгә керү өчен кәрәзле телефон: 89600674068 (татар теле һәм әдәбияты укытучысы Яковлева Гөлнур Фәтих кызы).

7.4. Конференциядә катнашу өчен, гариза-заявка түбәндәге формада җибәрелә: кушымта №1

## VIII. Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау

Фәнни-тикшерү конференциясендә катнашучыларның чыгышы алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә.

Катнашучыларның чыгышларын тыңлап бетергәннән соң, эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла.

Эксперт комиссиясенең карары протоколлаштырыла.

Фәнни-гамәли конференциядә җиңүчегә дипломнар, сертификатлар, рәхмәт хатлары 24 нче февральдән соң гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелә.

*Кушымта №1*

Факил Сафин иҗатына багышланган
V төбәкара фәнни-гамәли конференциясендә катнашу өчен
гариза

| | |
|---|---|
| Эшнең темасы | |
| Юнәлеш | |
| Катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (тулысынча) | |
| Укытучылар өчен – фәнни дәрәҗәсе, квалификацион категориясе<br>Укучылар өчен – сыйныф, җитәкченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | |
| Оешма исеме (Устав буенча), адресы, телефоны | |
| Катнашучының телефоны, электрон адресы | |